МИНИСТЕРСТВО ЗЕМЕЛЬНЫХ И ИМУЩЕСТВЕННЫХ ОТНОШЕНИЙ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ҖИР ҺӘМ МӨЛКӘТ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

21.01.2019 Казан № 15-пр

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 2017 елның 9 июнендәге № 1300-р карары белән расланган Россия Федерациясе гражданнарына үзләре били торган, Татарстан Республикасының казна мөлкәте булып торган торагын милеккә тапшыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Законнарга үзгәрешләр кертелүгә бәйле рәвештә боерам:

«Россия Федерациясе гражданнарына үзләре били торган, Татарстан Республикасының казна мөлкәте булып торган торагын милеккә тапшыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын турында» Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 2017 елның 9 июнендәге № 1300-р карары белән расланган Россия Федерациясе гражданнарына үзләре били торган, Татарстан Республикасының казна мөлкәте булып торган торагын милеккә тапшыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган тәкъдим ителгән үзгәрешләрне расларга

**Министр** **А.К.Хамаев**

_____________№ __________________ боерыгына тарату исемлеге

| № п/п | Адресат | Саны (данә) | Мөһер (+/-) | Җиткерү ысулы (+/-) | | | Адрес (почта аша китерелгәндә) |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | почта | кулга | «ЭД» системасында | |
| 1. | Хокук идарәсе | 1 | | | | + | |
| 2. | Торак күчемсез мөлкәт, торак-коммуналь һәм юл хуҗалыклары бүлеге | 1 | | | | + | |
| 3. | Исәпләү, мониторинг һәм мәгълүмати хезмәттәшлек идарәсе | 1 | | | | + | |

И.Г.Евченко
221-40-16

Татарстан Республикасы
Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре
министрлыгының
21.01.2019 №15-пр
карары белән расланды

«Россия Федерациясе гражданнарына үзләре били торган, Татарстан Республикасының казна мөлкәте булып торган торагын милеккә тапшыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 2017 елның 9 июнендәге № 1300-р карары белән расланган Россия Федерациясе гражданнарына үзләре били торган, Татарстан Республикасының казна мөлкәте булып торган торагын милеккә тапшыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр

1 бүлектә:

1.3.1 подпунктның икенче абзацын түбәндәге җөмлә белән тулыландырырга:

«Гаризалар кабул итү графигы: шимбә һәм якшәмбедән кала көн саен, Министрлык эшләгән сәгатьләрдә»

1.3.4 подпунктта:

беренче абзацка «дәүләт хезмәте» дигән сүзләрдән соң «, шулай ук, Министрлыкның урнашу урыны һәм эш графигы» дигән сүзләрне өстәргә;

2 подпунктның өченче абзацында «(http://uslugi.tatar.ru/)» сүзләрен «(http://uslugi.tatarstan.ru)» сүзләренә алмаштырырга;

тугызынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә бирелгән мәгълүмати стендлардагы мәгълүмат әлеге Регламентның 1.3.1, 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.8, 2.10, 2.11, 5.1 пунктлардагы дәүләт хезмәте турындагы белешмәне үз эченә ала.»;

1.5 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«күпфункцияле үзәкнең дәүләти һәм муниципаль хезмәт күрсәтүче ераклаштырылган эш урыны – Татарстан Республикасының муниципаль районнардагы (шәһәр округында) шәһәр һәм авыл җирлекләрендә «Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәк эшчәнлеген оештыру тәртипләрен раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 22

декабрендәге № 1376 карары белән расланган Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәк эшчәнлеген оештыру тәртипләренең 34 нче пункты нигезендә оештырылган дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкнең территориаль аерымланган структур подразделениесе (офис);»;

2 бүлектә:

2.4 пунктның «Стандартка таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт хезмәте гариза кергәннән соң 38 эш көне эчендә күрсәтелә.
Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору срогы каралмаган.»;

2.5 пунктта «Стандартка таләпләр эчтәлеге» графасына түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Гариза һәм аңа теркәлгән документларны гариза бирүче кәгазь форматта түбәндәге ысуллар белән тапшыра (җибәрә) ала:

шәхсән үзе (ышанычнамә нигезендә гариза бирүче исеменнән эш итүче зат);

почта аша.»;

2.6 пунктның «Стандартка таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Ведомствоара мәгълүмати арадашлык кысаларында алыналар:

күчемсез милек объектына төп характеристика һәм теркәлгән хокуклар турында Күчемсез милек бердәм дәүләт реестрыннан (алга таба – ЕГРН) өземтә - Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Федераль идарәсеннән (алга таба – ТР буенча Росреестр);

аерым затның үзендә булган күчемсез милеккә хокук (хокуклар) турында ЕГРН өземтәсе.

Гариза бирүче әлеге пунктта күрсәтелгән белешмәләр булган документларны үзе тапшыра ала, шул исәптән, мөмкинлек булган очракта электрон формада да.

Гариза бирүченең өстә күрсәтелгән белешмәләр булган документларны тапшырмавы дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тартуга сәбәп булып тормый.

Гариза бирүче тапшырырга хокуклы документларын алу һәм тапшыру тәртибе әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән.

Гариза бирүчедән түбәндәгеләрне таләп итү тыела:

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче органнарында, башка дәүләт органнарында, җирле үзидарә органнарында яисә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүдә катнашучы башка дәүләт органнары яки җирле үзидарә органнарының ведомствосында булган һәм башка оешмаларда булган документларны. Искәрмә булып №210-ФЗ Федераль законның 7 статьясындагы 6 өлешендә каралган документлар тора.

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны кабул итүдән беренчел баш тартканда белешмәнең булмавы һәм (яки) дөрес булмавы күрсәтелмәгәндә. Түбәндәге очраклар искәрмә булып тора:

дәүләт хезмәте күрсәтү турында беренче тапкыр документлар тапшырганнан соң, дәүләт хезмәте күрсәтүгә кагылышлы норматив хокукый актларның таләпләре үзгәрү;

документлар кабул итүдән беренче тапкыр баш тартканнан соң, дәүләт хезмәте күрсәтү турында мөрәҗәгатьтә һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен яисә дәүләт хезмәте күрсәткәндә зарури булган һәм алдан тапшырылган документлар комплектына кертелмәгән документларда хаталар булуы;

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен яисә дәүләт хезмәте күрсәткәндә зарури булган документлар кабул итүдән беренче тапкыр баш тартканнан соң, документларның срогы чыгуы яки мәгълүматның үзгәрүе;

дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының, дәүләт хезмәткәренең дәүләт хезмәте күрсәтү өчен яисә дәүләт хезмәте күрсәткәндә зарури булган документлар кабул итүдән беренче тапкыр баш тартканда хаталы яки хокукларга каршы гамәленең (гамәл кылмавының) документаль расланган факты (билгеләре) ачыклануы. Бу хакта гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүче орган җитәкчесе имзасы куелган хат аша белдерелә, кыенлык тудырылуы өчен гафу үтенелә.»;

2.13 пунктның «Стандартка таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Гариза һәм документлар кергән бер көн эчендә.

«Электрон формада ял көне (бәйрәм көнендә) кергән запрос ял көненнән (бәйрәмнән) соң килгән эш көнендә регистрацияләнә»;

2.15 пунктның унынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Министрлык белгечләре тарафыннан әлеге Регламентның бозылуы турында нигезле шикаятьләр булмау;»;

3 бүлектә:

3.1.1 подпунктын түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

«дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә киткән техник хаталарны төзәтү.»;

3.4.1 подпунктның дүртенче абзацында «сигез көнлек» сүзләрен «бер эш көне эчендә» сүзләре белән алмаштырырга;

3.5.1 подпунктның бишенче абзацында «ун көнлек» сүзләрен «өч эш көне эчендә» сүзләре белән алмаштырырга.»;

3.5.3 подпунктның икенче абзацында «дүрт көнлек» сүзләрен «бер эш көне эчендә» сүзләре белән алмаштырырга;

3.5.5 подпунктның икенче абзацында «сигез көнлек» сүзләрен «бер эш көне эчендә» сүзләре белән алмаштырырга;

3.5.6 подпунктның икенче абзацында «өч көнлек» сүзләрен «бер эш көне эчендә» сүзләре белән алмаштырырга;

3.5.8 подпунктның икенче абзацында «дүрт көнлек» сүзләрен «ике эш көне эчендә» сүзләре белән алмаштырырга;

3.5.10 подпунктның икенче абзацында «бер көн» сүзләрен «бер эш көне» дип тулыландырырга;

3.6.1 подпунктның икенче абзацында «бер көн» сүзләрен «бер эш көне» дип тулыландырырга;

3.6.3 подпунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Гариза бирүче торакны тапшыру турында карар регистрацияләнгәннән соң унтугыз эш көне эчендә тапшыру турында шартнамәне имзалый һәм Министрлыкка бирә.»;

3.6.4 подпунктның өченче абзацында «ике көн» сүзләрен «бер эш көне» сүзләренә алмаштырырга;

3.8 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә киткән техник хаталарны төзәтү»;

4 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«**4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тоту тәртибе һәм формалары**

4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ процедуралар белән билгеләнгән гамәлләр эзлеклелеге саклануын контрольдә тотуны дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы идарә (бүлек) җитәкчеләре әлеге Регламент нигезләмәләрен үтәү һәм башкаруны тикшереп тору юлы белән гамәлгә ашыра.

4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүне Министрлыкның вазыйфаи затлары контрольдә тота. Контрольдә тотучы вазыйфаи затларның вәкаләтләре Министрлык идарәләре (бүлекләре) турында нигезләмәләр һәм вазыйфаи регламентлар белән билгеләнә.

4.3. Агымдагы контроль Министрлыкның вазыйфаи затларының дәүләт хезмәте күрсәтү таләпләрен билгеләүче әлеге Регламент нигезләмәләрен һәм башка норматив актларны үтәвен һәи башкаруын тикшереп тору юлы белән гамәлгә ашырыла.

Агымдагы контроль даими алып барыла.

4.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын контрольдә тоту тикшерүләр үткәрүне, гариза бирүчеләрнең дәүләт хезмәте күрсәтүче вазыйфаи затларның кылган (кылмаган) гамәлләре турында шикаятьләр булган мөрәҗәгатьләрен карап, карарлар кабул итүне һәм гариза бирүченең мөрәҗәгатенә җаваплар әзерләүне үз эченә ала.

Административ процедураларның үтәлешен контрольдә тоту формалары булып түбәндәге тикшерүләр тора:

эш башкаруны алып бару;

документлар карау нәтиҗәләренең закон таләпләренә (әлеге Регламентка) туры килүе;

документлар кабул итү срокларын һәм тәртибен саклау;

дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә нәтиҗәләр бирү срогы һәм тәртибе саклану.

Тикшерүләр үткәрү даимилеге планлы (эш планнары нигезендә гамәлгә ашырыла) һәм планнан тыш булырга мөмкин (гариза бирүченең мөрәҗәгате буенча).

4.5. Дәүләт хезмәт күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын планнан тыш тикшерү үткәрү турында карар түбәндәге очракларда кабул ителә:

1) әлеге Регламент нигезләмәләренең һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә таләпләр куючы башка норматив актларның таләпләре бозылуы ачыкланып, аларның төзәтелгәнен тикшерүгә бәйле рәвештә;

2) Министрлыкның дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы вазыйфаи затларының гамәлләре (гамәл кылмаулары) гариза бирүчеләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен бозган очракта, гариза бирүчеләрнең мөрәҗәгать итүләренә бәйле рәвештә.

4.6. Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча гариза бирүчеләрнең хокукларын бозулар ачыкланган очракта, гаепле дип танылган дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы вазыйфаи затлар Россия Федерациясе законы нигезендә җаваплылыкка тартыла.

4.7. Дәүләт хезмәте күрсәтүне гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары ягыннан контрольдә тоту Идарә (бүлек) эшчәнлегенең дәүләт хезмәте күрсәтүдәге ачыклыгы, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм дөрес мәгълүмат алу һәм дәүләт хезмәте күрсәтү барышында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр карау мөмкинлеге аша гамәлгә ашырыла.»;

5 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

**«5. Министрлыкның, Министрлыкның вазыйфаи затларының яисә дәүләт хезмәткәрләренең карарларына, кылган (кылмаган) гамәлләренә карата судка кадәр (судтан тыш) тәртиптә шикаять белдерү**

5.1. Гариза бирүчеләр дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы Министрлыкның, Министрлыкның вазыйфаи затының яисә дәүләт хезмәткәренең карарларына һәм кылган (кылмаган) гамәлләрен зарланып судка кадәр Министрлыкка шикаять бирергә хокуклы.

Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча министрның карарына, кылган (кылмаган) гамәленә шикаять Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына бирелә

5.2. Гариза бирүче түбәндәге очракларда да шикаять белән мөрәҗәгать итә ала:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза бирүченең запросын теркәү срогы бозылганда;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү срогы бозылганда;

3) гариза бирүчедән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен Россия Федерациясенең норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив-хокукый актларында күздә тотылмаган документлар яки мәгълүмат, гамәлләр кылуны таләп иткәндә;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен гариза бирүчедән Россия Федерациясе норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив-хокукый актларында күздә тотылган документларны кабул итеп алудан баш тартканда;

5) дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартканда, әгәр баш тартуга нигезләр федераль законнар һәм Россия Федерациясенең алар нигезендә кабул ителгән башка норматив-хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары һәм норматив-хокукый актлары нигезендә күздә тотылмаса;

6) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен гариза бирүчедән Россия Федерациясенең норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив-хокукый актларында күздә тотылмаган түләү таләп иткәндә;

7) Министрлык, Министрлыкның вазыйфаи заты дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документлардагы ялгыш язуларны һәм хаталарны төзәтүдән баш тартканда яки мондый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозганда;

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе буенча документлар бирү срогын яки тәртибен бозганда;

9) дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатканда, әгәр андый туктату федераль законнар һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары белән каралмаган булса.

10) дәүләт хезмәте күрсәткәндә гариза бирүчедән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен яисә дәүләт хезмәте күрсәткәндә зарури булган документлар кабул итүдән беренче тапкыр баш тартканда булмавы яки дөрес түгеллеге күрсәтелмәгән мәгълүматны яки документларны таләп итү. №210-ФЗ Федераль законның 1 статьясындагы 4 өлешендә каралган очраклар искәрмә булып тора.

5.3. Шикаять язмача кәгазьдә яисә электрон формада бирелә.

Шикаять почта аша, күпфункцияле үзәк аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдаланып, Министрлыкның рәсми сайты (http://mzio.tatarstan.ru), Татарстан Республикасының Дәүләти һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләр порталы (http://uslugi.tatarstan.ru), Дәүләти һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы (http://www.gosuslugi.ru) аша җибәрелергә, шулай ук гариза бирүчене шәхсән кабул итү барышында кабул ителергә мөмкин.

5.4. Шикаять түбәндәге мәгълүматлардан торырга тиеш:

1) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның атамасы, аның карарларына һәм кылган (кылмаган) гамәлләренә шикаять белдерелгән дәүләт хезмәте күрсәтүче вазыйфаи затының яки дәүләт хезмәткәренең исеме;

2) гариза бирүченең фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (соңгысы - булганда), гариза бирүче физик затның яшәү урыны турында мәгълүматлар яисә гариза бирүче юридик затның урнашкан урыны турында мәгълүматлар, шулай ук элемтәгә керү өчен телефон номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булганда) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә тиешле почта адресы;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, аның дәүләт хезмәте күрсәтүче вазыйфаи затының яки дәүләт хезмәткәренең шикаять белдерелә торган карарлары һәм кылган (кылмаган) гамәлләре турында белешмә;

4) гариза бирүченең нәрсәләр нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтүче органның карары һәм кылган (кылмаган) гамәлләре белән килешмәвенә, нәрсәләр нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтүче вазыйфаи затның яки дәүләт хезмәткәренең карары һәм кылган (кылмаган) гамәлләре белән килешмәвенә дәлилләре.

5.5. Гариза бирүче күрсәтелгән шартларны раслый торган документларны (булса) яки аларның күчермәләрен тапшыра ала.

5.6. Шикаятьне карап тикшерү вакыты – аны регистрацияләгәннән соң 15 көн. Министрлыкның гариза бирүчедән документларын кабул итеп алудан баш тартуга яки ялгыш язуларны һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуга яки мондый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозуга карата шикаять белдерелгән очракта - аны теркәгән көннән алып биш эш көне эчендә.

5.7. Шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаятьне канәгатьләндерә, шул исәптән кабул ителгән карарны юкка чыгару рәвешендә, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән ялгыш язуларны һәм хаталарны төзәтү, Россия Федерациясенең норматив-хокукый актлары, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актлары нигезендә түләтү күздә тотылмаган акчаларны гариза бирүчегә кире кайтарып бирү рәвешендә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

5.8. Әлеге Регламентның 5.7 пунктында күрсәтелгән карар кабул ителгәннән соң килүче көннән дә соңга калмыйча, гариза бирүчегә язмача һәм, гариза бирүченең теләгенә карап, электрон рәвештә, шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре турында нигезле җавап җибәрелә.

5.9. Шикаять канәгатьләндерелә дип танылган очракта, гариза бирүчегә Регламентның 5.8 пунктында күрсәтелгән җавапта дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә ачыкланган тәртип бозуларны бетерү максатында Министрлык кылган гамәлләр

турында мәгълүмат бирелә, тудырылган уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә, гариза бирүче дәүләт хезмәте алу өчен кылырга тиешле гамәлләр турында мәгълүмат китерелә.

5.10. Шикаять канәгатьләндерелми дип танылган очракта, гариза бирүчегә Регламентның 5.8 пунктында күрсәтелгән җавапта кабул ителгән карарның сәбәпләре ачыклана, кабул ителгән карарга шикаять белдерү тәртибе турында мәгълүмат бирелә.

5.11. Шикаятьне карау барышында яки аның нәтиҗәләре буенча, административ хокук бозу билгеләре яки җинаять ачыкланса, шикаятьләрне карау вәкаләтләре бирелгән вазыйфаи зат булган материалларны тиз арада прокуратура органнарына юллый.»;

Приложение (справочное) к Административному регламенту предоставления государственной услуги по передаче в собственность граждан Российской Федерации занимаемых ими жилых помещений, составляющих имущество казны Республики Татарстан изложить в следующей редакции:

Россия Федерациясе гражданнарына үзләре били торган, Татарстан Республикасының казна мөлкәте булып торган торагын милеккә тапшыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кушымта (белешмәлек)

Россия Федерациясе гражданнарына үзләре били торган, Татарстан Республикасының казна мөлкәте булып торган торагын милеккә тапшыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы булган вазыйфаи затларның реквизитлары

**Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы**

| **Вазыйфа** | **Телефон** | **Электрон адрес** |
|---|---|---|
| Министр<br>Хамаев Азат Кыям улы | 221-40-00 | mzio@tatar.ru |
| Министрның беренче урынбасары<br>Галиев Артур Ирек улы | 221-40-01 | mzio@tatar.ru |

| | | |
|---|---|---|
| Торак күчемсез мөлкәт, торак-коммуналь һәм юл хуҗалыклары бүлеге мөдире | 221-40-28 | |
| Канцелярия эшләрен алып бару һәм контрольдә тоту бүлеге мөдире Румянцева Гөлнур Нияз кызы | 221-40-81 | Gulnur.Rumyanceva@tatar.ru |

**Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты, Икътисад, финанс һәм дәүләт мөлкәте белән эш итү идарәсе**

| **Вазыйфа** | **Телефон** | **Электрон адрес** |
|---|---|---|
| Икътисад, финанс һәм дәүләт мөлкәте белән эш итү идарәсе начальнигы Гайнетдинов Ренат Вагыйз улы | 264-77-22 | Renat.Gaynutdinov@tatar.ru |
| Дәүләт мөлкәте белән эш итү бүлеге Рогожкин Максим Анатольевич | 264-76-22 | Maksim.Rogozhkin@tatar.ru» |